РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» июль 2022 ел Олы Кайбыч ав. № 130

Кайбыч муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында 2016 елның 04 ноябрендәге 29 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Нигезләмәгә, 8 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«3) (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, ул килешүгә кул куелганчы, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр».

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль

берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2014 елның 18 октябрендәге 242 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Нигезләмәгә, 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«в) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, һәм алар хисабына алыш-биреш ясалган керем алу чыгынаклары турында килешү төзелгән хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), белешмәләр.»;

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында Кайбыч муниципаль районы Советының 2011 елның 17 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, һәм алар хисабына алыш-биреш ясалган керем алу чыгынаклары турында килешү төзелгән хисап чоры өчен белешмәләр.».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе Р. Г. Айзатуллоавага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин